СОВЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**22 март 2024 ел** **№10**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Үрнәк авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыенының беренче этабын Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан Урта Пошалым мәдәният йорты бинасында 2024 елның 6 апрелендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыенының икенче этабын Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт адресы буенча урнашкан Урта Пошалым мәдәният йорты бинасында 2024 елның 6 апрелендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3.Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1 нче этап: Х.Такташ урамында яшәүчеләр.
2 нче этап: Вахитов, Сәйдәшев урамнарында яшәүчеләр.

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Урта Пошалым авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- (җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү, торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Х.Такташ урамындагы күперне ремонтлау)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Урта Пошалым авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Арча районы, Урта Пошалым авылы, Вахитов урамы, 15 нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan. ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков